МИНИСТЕРСТВО ФИНАНСОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ФИНАНС МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

17.10.2019 № 21-53-244

Казан ш.

Татарстан Республикасы алдындагы акча йөкләмәләре буенча бурычны учетта исәптән төшерү һәм торгызу кагыйдәләрен (нигезләре, шартлары һәм тәртибе) билгеләү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының $93^{7}$ статьясындагы 3 пункты Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $24^{1}$ статьясындагы 3 пункты нигезендә, боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы алдындагы акча йөкләмәләре буенча бурычны учетта исәптән төшерү һәм торгызу кагыйдәләрен (нигезләре, шартлары һәм тәртибе) (кушымта итеп бирелә) расларга.

2. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментына бу боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына дәүләт теркәвенә алуга җибәрергә.

3. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Министр Р.Р.Гайзатуллин

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 17.10.2019 ел, №21-53-244 боерыгы белән расланды

# Татарстан Республикасы алдындагы акча йөкләмәләре буенча бурычны учетта исәптән төшерү һәм торгызу кагыйдәләре

## I.Гомуми нигезләмәләр

Бу Кагыйдәләр Татарстан Республикасы тарафыннан кире кайтару һәм түләү (кире кайтару) нигезендә акча средстволарын бирүгә һәм (яки) дәүләт гарантиясен бирүгә һәм (яки) үтәүгә бәйле рәвештә килеп чыккан Татарстан Республикасы алдындагы акчалата йөкләмәләр буенча бурычны учетта Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан исәптән төшерү һәм торгызу нигезләрен, шартларын һәм тәртибен билгели.

Татарстан Республикасы алдындагы акчалата йөкләмәләр буенча бурыч булып бурычлы (муниципаль берәмлек, юридик зат, хосусый эшмәкәр, физик зат) тарафыннан билгеле бер датага Татарстан Республикасы алдындагы акчалата йөкләмә нигезендә түләнергә тиешле акча средстволары суммасы (алга таба – бурыч) тора.

## II.Акчалата йөкләмәләр буенча бурычны исәптән төшерү өчен нигезләр һәм шартлар

2.1.Түләтүгә өмет булмаган бурыч исәптән төшерелергә тиеш.

2.2. Түбәндәге очракларда бурыч түләтүгә өмет булмаган бурыч дип танылa:

2.2.1. Бурычлы физик зат үлгән очракта яки ул Россия Федерациясе гражданлык-процессуаль законы нигезендә билгеләнгән тәртиптә үлгән дип игълан ителгән очракта.

2.2.2. Бурычлы хосусый эшмәкәр “Бөлгенлеккә төшү (банкротлык)” турында 26 октябрь, 2002 ел, № 127-ФЗ Федераль закон нигезендә банкрот дип танылган очракта.

2.2.3. Юридик затның мөлкәте җитәрлек булмау аркасында бурычлы булып калган һәм (яки) әлеге юридик затның гамәлгә куючылары (катнашучылар) аны түләү мөмкинлегенә ия булмау сәбәпле бурычлы юридик затны юкка чыгару очрагында.

2.2.4. Суд тарафыннан акт кабул ителеп, аның нигезендә, бурычны түләтүнең билгеләнгән срогы (дәгъва срогы) чыгу сәбәпле, Татарстан Республикасы акчалата йөкләмәләр буенча бурычны түләтү мөмкинлеген югалткан очракта, шул исәптән акчалата йөкләмәләр буенча бурычны түләтү турында судка гариза тапшыруның кулдан ычкындырылган срогын торгызудан баш тарту хакында суд билгеләмә чыгарганда.

2.2.5. Бурыч барлыкка килүгә биш елдан артыграк вакыт узган очракта суд приставы-башкаручы “Башкару производствосы турында” 2 октябрь, 2007 ел, № 229-ФЗ Федераль законның 46 статьясындагы бер өлешенең 3 һәм 4 пунктларында

күздә тотылган нигезләр буенча башкару производствосының төгәлләнүе һәм түләтүчегә башкару документын кире кайтару турында карар чыгарганда.

2.2.6. Гамәлдә булмаган юридик затны теркәү органы карары буенча Юридик затларның бердәм реестрыннан төшереп калдырганда.

## III.Бурычны түләтүгә өмет булмаган бурыч дип тану турында карарлар кабул итү өчен кирәкле документлар исемлеге

3.1. Бурычны түләтүгә өмет булмаган бурыч дип тану турында карар, бу Кагыйдәләрнең 2.2 пунктындагы 2.2.1 пунктчасында күрсәтелгән очракта, түбәндәге нигездә кабул ителә:

а) бу Кагыйдәләргә № 1 кушымта нигезендәге форма буенча акчалата йөкләмә буенча баланс (баланстан тыш) счетында исәпкә алына торган бурыч суммалары турында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы хисабыннан өземтәләр (алга таба – өземтә);

б) Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаменты анализ һәм стратегия бүлеге тарафыннан Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының юридик бүлеге белән берлектә яки Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының бюджет сәясәте бүлеге тарафыннан Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының юридик бүлеге белән берлектә тапшырылган бурычны түләтүне тәэмин итү буенча күрелгән чаралар турында белешмәләр (алга таба – белешмә);

в) бурычлы физик затның үлүе турында раслаучы яки аны үлгән дип игълан хатын раслаучы документ.

3.2. Бу Кагыйдәләрнең 2.2 пунктындагы 2.2.2 пунктчасында күрсәтелгән очракта, бурычны түләтүгә өмет булмаган бурыч дип тану турында карар түбәндәге нигездә кабул ителә:

а) өземтә;

б) белешмә;

в) Хосусый эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан бурычлы хосусый эшмәкәрне банкрот дип тану аркасында эшчәнлеген туктату турында мәгълүматлардан торган документ.

3.3. Бу Кагыйдәләрнең 2.2 пунктындагы 2.2.3 пунктчасында күрсәтелгән очракта, бурычны түләтүгә өмет булмаган бурыч дип тану турында карар түбәндәге нигездә кабул ителә:

а) өземтә;

б) белешмә;

в) Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 61 статьясындагы 2 пунктында күрсәтелгән нигезләр буенча юридик затны юкка чыгару турында суд карары күчермәсе яки гамәлгә куючылары (катнашучылар) яисә гамәлгә кую документлары нигезендә вәкаләт бирелгән юридик зат органы карары күчермәсе;

г) Хосусый эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан бурычлы юридик затны бетерүгә бәйле рәвештә эшчәнлеген туктату турында мәгълүматлардан торган документ.

3.4. Бу Кагыйдәләрнең 2.2 пунктындагы 2.2.4 пунктчасында күрсәтелгән очракта, бурычны түләтүгә өмет булмаган бурыч дип тану турында карар түбәндәге нигездә кабул ителә:

а) өземтә;

б) белешмә;

в) суд акты, аның нигезендә, бурычны түләтүнең билгеләнгән срогы (дәгъва срогы) чыгу сәбәпле, Татарстан Республикасы акчалата йөкләмәләр буенча бурычны түләтү мөмкинлеген югалткан очракта, шул исәптән акчалата йөкләмәләр буенча бурычны түләтү турында судка гариза тапшыруның кулдан ычкындырылган срогын торгызудан баш тарту хакында суд билгеләмәсе чыгарганда.

3.5. Бу Кагыйдәләрнең 2.2 пунктындагы 2.2.5 пунктчасында күрсәтелгән очракта, бурычны түләтүгә өмет булмаган бурыч дип тану турында карар түбәндәге нигездә кабул ителә:

а) өземтә;

б) белешмә;

в) “Башкару производствосы турында” 2 октябрь, 2007 ел, № 229-ФЗ Федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 һәм 4 пунктларында күздә тотылган нигезләр буенча башкару производствосының тәгәлләнүе һәм түләтүчегә башкару документының кире кайтарып бирелүе турында суд приставы-башкаручы карары.

3.6. Бу Кагыйдәләрнең 2.2 пунктындагы 2.2.6 пунктчасында күрсәтелгән очракта, бурычны түләтүгә өмет булмаган бурыч дип тану турында карар түбәндәге нигездә кабул ителә:

а) өземтә;

б) белешмә;

в) бурычлы юридик затны Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан чыгару турында мәгълүматлардан торган документ.

## IV.Татарстан Республикасы алдындагы акчалата бурычлар буенча бурычны учеттан төшерү (торгызу) тәртибе

4.1. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык Департаментының анализ һәм стратегия бүлеге Татарстан Республикасы тарафыннан кире кайтару һәм түләүле (кире кайтару) нигездә акчалата средстволар бирелүгә бәйле рәвештә килеп чыккан бурычка карата яки Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының бюджет сәясәте бүлеге дәүләт гарантиясен бирүгә һәм (яки) үтәүгә бәйле рәвештә килеп чыккан бурычка карата, бу Кагыйдәләрнең III бүлеге нигезендә, бурычны түләтүгә өмет булмаган бурыч дип тануның нигезен раслаучы документлар пакетын әзерли һәм аларны Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Активлар керү һәм чыгу комиссиясенә (алга таба – Комиссия) җибәрә.

4.2. Комиссия тапшырылган документларны кабул ителгән көннән башлап, эш көннәрендә исәпләнелә торган 10 көнлек срокта карап тикшерә. Комиссиянең һәр акчалата йөкләмә буенча карары индивидуаль кабул ителә.

4.3. Комиссия документларны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) бурычны түләтүгә өметсез бурыч дип тану һәм аны балланстан төшереп калдыру турында;

б) бурычны түләтүгә өметсез бурыч дип танудан баш тарту турында. Әлеге карар әлеге бурычны түләтүгә өметсез бурыч дип тану турында мәсьәләне кабат карап тикшерүгә комачауламый.

4.4. Комиссия карары, утырышта катнашучы Комиссия әгъзаларының күпчелек тавышы белән, ачык тавыш бирү нигезендә кабул ителә. Тавышлар бертигез булганда, Комиссия рәисе тавышы хәлиткеч дип санала.

4.5. Комиссия карары бу Кагыйдәләргә № 2 кушымта нигезендәге форма буенча акт (алга таба – акт) белән рәсмиләштерелә.

Акт ике нөсхәдә төзелә һәм Комиссия рәисе һәм утырышта катнашкан Комиссиянең барлык әгъзалары тарафыннан имзалана.

4.6. Комиссия бурычны исәптән төшерү турында акт тапшыра:

Татарстан Республикасы тарафыннан кире кайтару һәм түләүле (кире кайтару) нигезендә акча средстволары бирелүгә бәйле рәвештә килеп чыккан бурычка карата – Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаменты анализ һәм стратегия бүлегенә;

Дәүләт гарантиясен бирелүгә һәм (яки) үтәүгә бәйле рәвештә килеп чыккан бурычка карата – Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының бюджет сәясәте бүлегенә.

4.7. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаменты анализ һәм стратегия бүлеге Татарстан Республикасы тарафыннан кире кайтару һәм түләүле (кире кайтару) нигезендә акча средстволарын бирүгә бәйле рәвештә килеп чыккан түләтүгә өмет булмаган бурычка карата, яки Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының бюджет сәясәте бүлеге дәүләт гарантиясен бирүгә һәм (яки) үтәүгә бәйле рәвештә килеп чыккан түләүгә өмет булмаган бурычны балланстан төшерү турында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы боерыгы проектын әзерли.

4.8. Акчалата йөкләмәләр буенча түләүгә өмет булмаган бурычны бюджет (бухгалтерия) учетыннан төшерү, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының түләтүгә өмет булмаган бурычны балланстан төшерү турында боерыгы һәм акт (актлар) нигезендә, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының республика бюджеты учеты һәм хисап бүлеге тарафыннан хәл ителә.

4.9. Бау Кагыйдәләрнең 2.2 пунктындагы 2.2.1, 2.2.3 пунктчаларында күрсәтелгән очракларда, түләтүгә өмет булмаган, баланс учетыннан төшерелгән бурыч балланстан тыш учетка кире кабул ителми.

4.10. Бу Кагыйдәләрнең 2.2 пунктындагы 2.2.4, 2.2.5, 2.2.6 пунктчаларында күрсәтелгән очракларда түләтүгә өмет булмаган дип танылган һәм баланс учетыннан төшерелгән бурыч балланстан тыш учетка кабул ителә һәм Россия Федерациясе законы нигезендә бурычны түләү процедурасын ихтимал яңарту срогы дәвамында исәпкә алына, шул исәптән бурычлыларның мөлкәти хәле үзгәргән очракта, яисә күрсәтелгән срокка түләүгә сәләтсез дебиторлар бурычын түләүгә акча средстволары керүгә кадәр, Россия Федерациясе законына каршы килмәгән башка ысул белән бурычны үтәүгә (туктату) кадәр кабул ителә.

4.11. Баланстан тыш учетта бурычны күзәтү срогы тәмамланганнан соң, Татарстан республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының анализ һәм стратегия бүлеге Татарстан Республикасы тарафыннан ки ре кайтару һәм түләүле (кире кайтару) нигезендә акча средстволары бирелүгә бәйле рәвештә килеп чыккан бурычка карата яки Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының бюджет сәясәте бүлеге дәүләт гарантиясен бирүгә һәм (яки) үтәүгә бәйле рәвештә килеп чыккан бурычка карата бу Кагыйдәләрнең III бүлеге нигезендә документлар пакетын булдыра. Булдырылган документлар пакеты Комиссия тарафыннан бурычны алга таба мониторинглауның максатка ярашлы булу мәсьәләсен яки аны баланстан тыш учеттан төшерү мәсьәләсен карап тикшерү өчен җибәрелә.

Бюджет (бухгалтерия) учетында акчалата йөкләмәләр буенча түләтүгә өмет булмаган бурычны баланстан тыш учеттан төшерү, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының түләтүгә өмет булмаган бурычны баланстан тыш учеттан төшерү турында боерыгы һәм акт (актлар) нигезендә хәл ителә.

4.12. Бурычны түләтү процедурасын яңартканда яки бурычны түләүгә средстволар алынганда, түләтүне яңарту датасына яки әлеге акчаны счетка күчерү датасына, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының баланс учетында бурычны торгызу турында боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының республика бюджеты учеты һәм хисап бүлеге баланс учетында бурычны торгызуны хәл итә.

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының баланс учетында бурычны торгызу турында боерыгы проектын, Татарстан Республикасы тарафыннан кире кайтару һәм түләүле (кире кайтару) нигезендә акча средстволары бирүгә бәйле рәвештә килеп чыккан бурычка карата – Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык Департаменты анализ һәм стратегия бүлеге, дәүләт гарантиясен бирүгә һәм (яки) үтәүгә бәйле рәвештә килеп чыккан бурычка карата – Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының бюджет сәясәте бүлеге әзерли.

Татарстан Республикасы алдындагы акча йөкләмәләре буенча бурычны учетта исәптән төшерү һәм торгызу кагыйдәләренә (нигезләре, шартлары һәм тәртибе) № 1 кушымта

Баланс (баланстан тыш) счетта исәпкә алына торган акчалата йөкләмә буенча бурыч күләме турында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы хисабыннан
ӨЗЕМТӘ

______________________________________________________________________
(муниципаль берәмлек, юридик зат атамасы(ИНН), физик затның Ф.И.О. (ИНН – булганда),хосусый эшмәкәрнең Ф.И.О. (ИНН – булганда)

________________ 20__ елга акчалата йөкләмә атамасы

| № п/п | КБК | Акчалата йөкләмә атамасы | Килешү (шартнамә) датасы һәм номеры | Бурыч күләме, сум. |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |

________________ ______________
Бүлек начальнигы (имза) (Ф.И.О.)

________________________________________ ____________
Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының учет һәм хисап бүлеге начальнигы
(имза) (Ф.И.О.)

Татарстан Республикасы алдындагы акча йөкләмәләре буенча бурычны учетта исәптән төшерү һәм торгызу кагыйдәләренә (нигезләре, шартлары һәм тәртибе) № 2 кушымта

АКТ № ___

«__» ___________ 20___ ел Казан ш.

Комиссия Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Активлар керү һәм чыгу комиссиясе тапшырылган документлар нигезендә ____________<*> мәсьәләне карады ______________________________________________________

_______________________________________________________________________________
(муниципаль берәмлек, юридик зат атамасы(ИНН), физик затның Ф.И.О. (ИНН – булганда),хосусый эшмәкәрнең Ф.И.О. (ИНН – булганда)

_______________________________________________________________________________

акчалата йөкләмә буенча
_______________________________________________________________________________
(бурыч китереп чыгарган акчалата йөкләмә турында мәгълүматлар <**>, бурычны исәпкә алу өчен КБК, аның атамасы)

бурыч күләме - ___________________________________________.
(саннар һәм сүзләр белән күрсәтелә)

Комиссия карар кабул итте:
______________________________________________________________________________.
(Татарстан Республикасы алдында акчалата йөкләмәләр буенча бурычны учеттан төшерү һәм торгызу кагыйдәләренең (нигезләре, шартлары һәм тәртибе) 4.3,4.11 пунктлары нигезендә Комиссия тарафыннан кабул ителгән карарларның берсе күрсәтелә)

Акт 2 нөсхәдә төзелде.

Комиссия рәисе: ____________________ ____________________
(Ф.И.О.) (имза)

Комиссия әгъзалары: ____________________ ____________________
(Ф.И.О.) (имза)

____________________ ____________________
(Ф.И.О.) (имза)

____________________ ____________________
(Ф.И.О.) (имза)

____________________ ____________________
(Ф.И.О.) (имза)

--------------------------------

<*> - документлар атамалары һәм реквизитлары күрсәтелә.

<**> - бурыч китереп чыгарган акчалата йөкләмәләр, таләпләр куюга нигез итеп алынган документлар (карарлар, һ.б.) атамалары һәм реквизитлары күрсәтелә.